ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 06 2021 г. № 144

**Татарстан Республикасы Балтач район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Балтач район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибен расларга.

2. Җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгына ярты елның соңгы аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр елга ике тапкыр гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба - анализ) ясарга.

3. Балтач район Советының оештыру бүлеге баш белгеченә соңгы айдан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча анализны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

4.Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы — Р. Р. Нотфуллин

Балтач муниципаль районы башлыгының 2021 елның «03» 06 144 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балтач район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Анализ үткәрелгәндә кергән, башкаларга кергәнне җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең саны, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булган очракта) турында мәгълүмат өйрәнелә.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә бирелгән язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ һәм мәгълүмат нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советының Җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге (алга таба - бүлек) башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы, аның урынбасарының (алга таба - җитәкчелек) шәхси кабул итүләрендә кергән мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балтач район Советының оештыру бүлеге һәм Татарстан Республикасы Балтач район Советының Җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлегенең әйдәп баручы белгечләренә тапшырыла.

5. Күчмә кабул итүләр буенча мәгълүмат башкаручылар тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач район Советының Җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгына бирелә.

6. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат Балтач район Советының оештыру бүлеге һәм Балтач район Советының Җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлегенең әйдәп баручы белгечләре тарафыннан 5 числога кадәр бирелә.

7. Мөрәҗәгатьләргә анализ Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру өчен Балтач район Советының оештыру бүлеге баш белгеченә җибәрелә. Анализ Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында ярты елның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

8. Татарстан Республикасы Балтач район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык ачык мәгълүмат булып тора.